ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧУБУКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЫБЫКЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«20» декабрь 2018 ел** **№23**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

В соответствии с Бюджетным кодексом Российской Федерации, Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 24 марта 2004 года № 23-ЗРТ «О местном референдуме», Уставом Чубуклинского сельского поселения, решением Совета Чубуклинского сельского поселения Заинского муниципального района от «27» февраля 2014 года №129 «О самообложении граждан», Исполнительный комитет Чубуклинского сельского поселения постановил:

1. Чыбыклы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Н. Гадершин**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Чыбыклы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 20 декабрендәге
23 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Чыбыклы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары киләсе календарь елның 15 февраленә кадәр Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, җирле референдумда (җыенда) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан түләнә.

3. Түләми тору өчен нигезле сәбәпләр булып түбәндәгеләр торырга мөмкин:

а) вакытлыча хезмәткә яраксызлык (6 айдан артык),

б) оешманы бетерү, оешма хезмәткәрләренең санын яки штатын кыскарту сәбәпле эштән азат ителү,

гражданнарга гариза нигезендә түләүне кичектерү ике айдан да артык булмаган вакытка бирелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерү) бланкы турында гражданнарга хәбәр җирлекнең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру, кул куйдырып, кулга бирү юлы белән житкерелә, почта элемтәсе аша җибәрелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган документлар булып приход касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Чыбыклы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 20 декабрендәге
23 номерлы карарына
2 нче кушымта

________________________ авыл җирлеге бюджетына бер тапкыр түләнә торган салымны түләү турында ______ номерлы

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮ)

Түләүченең
Ф.И.А. ____________________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
Сезгә ____________________________________________нигезендә ______________________
вакытында кадәр ___________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр ____________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча салым түләргә кирәк.
Банк БИК ____________________________________________
Сч. № ________________________________________
Алучы Сч. № ________________________________________________
ИНН ________________________________________________
КПП ________________________________________________
КБК _________________ ОКАТО ____________________
Түләүнең
билгеләнеше____________________________________________________________

Җитәкче ____________________ ______________________________
М.У. (имза) (имза тулысынча)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерү) No ____
____________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча __________________ суммада бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.А. ________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
Алынган «__» __________________ 20__ ел______________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Өзеп бирелә торган квитанция тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылганда төпсә ______________ авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*